## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 20 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылы территориясендә I төркем инвалидлардан, олы яшьтәге ялгыз гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан, хөкем ителгәннәрдән, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Кужак торак пунктының Терешкова урамының бер өлешен ремонтлау(вак таш сатып алу, ташу, җәю,килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Кужак торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү ( лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Кужак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

4) Җәйге чорда Кужак торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, бензин белән эшли торган триммер сатып алу )

5) Кужак торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Иске Минзәләбаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми

сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А.Н.Габдрахманов